Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Мөслим авыл җирлеге башлыгы карары

11.02.2020 №1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Мөслим авыл җирлеге башлыгының
2016 елның 29 апрелендәге
10 номерлы карарының
үз көчен югалтуын тану хакында

«Муниципаль вазыйфа, яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны, яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 29 апрелендәге «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында»гы 10 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), Мөслим авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына элү юлы белән халыкка хәбәр итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга( http:/chistopol.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Мөслим авыл
җирлеге башлыгы Ш.А. Мәссаров